СОВЕТ ИМЕНИ ВОРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ВОРОВСКИЙ
ИСЕМЕНДЭГЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ ВОРОВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№1 17.09.2024 ел.

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» 17.09.2018 № 1 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 3. статьясы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Воровский исемендәге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 20.07.2020№ 236-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү турында», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 1 маендагы №87-ФЗ Федераль законга нигезләнеп, Воровский исемендәге авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРА:

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» 17.09.2018 елгы №1 карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 абзацның 1.6 пунктын кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«җирлек төзелгән авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта,яңа төзелгән җирлекне төзү турында халыкның инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия халык саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;»;

1.2. кушымтаның 1.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар жыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча.»;

1.3. Кушымтаның 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия торак пунктта яисә җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Әгәр торак пунктта сайлау хокукына ия булган әлеге торак пункт халкының яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены составына күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыенын уздыру турында Карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да артмаган вакытта этаплап үткәрелә. Моңа кадәр гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Гражданнар җыены карары өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Житәкче В.П.Елхов